ГЛАВА ДЮСЬМЕТЬЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Молодежная, д.17, с. Дюсьметьево, Мамадышский район, Республика Татарстан, 422150

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ДҮСМӘТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Яшьләр ур., 17 нче йорт, Дүсмәт авылы, Мамадыш районы, Татарстан Республикасы,422150

тел.(факс): (85563) 2-55-19; e-mail: Dusm..Mam@tatar.ru, www: mamadysh.tatarstan.ru

Карар　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　Постановление
“07” ноябрь 2019 ел　　　　　　　　　　　　　　　　№7

## Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Дүсмәт авыл җирлегенең Дүсмәт авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Дүсмәт авыл җирлеге муниципаль берәмлеге” Уставының 23 статьясы нигезендә карар бирәм :

1. Татарстан Республикасы, Мамадыш муниципаль районы, Дүсмәт авылы , Молодежная урамы , 17 нче йорт адресы буенча урнашкан Дүсмәт авылы мәдәният йорты бинасында 2019 елның 20 ноябрендә сәгать 11.00 дә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Дүсмәт авыл җирлегенең Дүсмәт авылы торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Дүсмәт авыл җирлегенең Дүсмәт торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2020 елда 400 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

- Комазанка елгасы аша күперне ремонтлау (материаллар сатып алу, торбаны алыштыру, килешү буенча эш өчен түләү);
-Дүсмәт торак пунктындагы юлларны тигезләү һәм кардан чистарту.

« ӘЙЕ» «ЮК».

3. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Дүсмәт авыл җирлеге башкарма комитетына Дүсмәт авылында гражданнар җыенын оештыруны һәм уздыруны йөкләргә .

4. Әлеге карарны кабул иткәннән соң 3 көн эчендә муниципаль берәмлек Советының мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Дүсмәт авыл җирлеге башлыгы: О.Н.Павлов